ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОШУГУРОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Советская ул., дом 1, село Старое
Шугурово, Лениногорский район,
423282

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ ШӨГЕР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 1 нче йорт, Иске Шөгер
авылы, Лениногорск районы, 423282

Тел.: (8-85595) 3-45-42, факс: (8-85595) 3-45-43, Sshug.Len@tatar.ru,
leninogorsk.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 28 октябре № 5

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Яңа Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер җирлегенең Яңа Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 20 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге Иске Шөгер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлар, хәрби хәрәкәт ветераннары, ветераннары һәм хәрби хәрәкәттә катнашучыларның тол калган хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, халык саны 18 яшькә җиткән җирлек халкының гомуми санынннан 30% тан артмаска тиеш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

1) балалар өчен спорт-уен инвентаре сатып алу;
тракторчы хезмәтләре өчен түләү (территорияне коры-сары һәм чүп үләннәреннән чабу, кардан чистарту, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3.Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Шөгер - җирле үзидарә бинасы, Совет урамы, 1 нче йорт, Совет урамы, 3 нче йорт буенча урнашкан балалар бакчасы бинасында, М. Җәлил урамы, 33 нче йорт, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М. Шиһапова